КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 5 ноябрь г.Казань № 914

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче, 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы, 2018 ел, 12 июль, 566 нчы, 2018 ел, 29 сентябрь, 884 нче, 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче, 2018 ел, 15 декабрь, 1138 нче, 2020 ел, 17 март, 192 нче, 2020 ел, 14 июль, 590 нчы, 2020 ел, 5 август, 656 нчы, 2020 ел, 28 декабрь, 1203 нче, 2021 ел, 7 октябрь, 959 нчы, 2021 ел, 7 декабрь, 1180 нче, 2022 ел, 12 март, 224 нче, 2022 ел, 31 октябрь, 1161 нче, 2023 ел, 16 июнь, 723 нче, 2023 ел, 26 сентябрь, 1185 нче, 2024 ел, 16 июль, 562 нче, 2024 ел, 19 август, 671 нче, 2024 ел, 9 сентябрь, 749 нчы, 2025 ел, 15 гыйнвар, 13 нче, 2025 ел, 27 март, 177 нче, 2025 ел, 3 июнь, 398 нче, 2025 ел, 11 июнь, 419 нчы, 2025 ел, 10 июль, 497 нче, 2025 ел, 25 август, 630 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.83 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«3.3.83. Үз компетенциясе кысаларында:

социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны сәнгать, техник һәм башка клубларда, түгәрәкләрдә, секцияләрдә дәресләргә җәлеп итүдә катнаша;

балигъ булмаганнарны ватан һәм дөнья мәдәнияте кыйммәтләренә җәлеп итәргә ярдәм итә;

социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган балалар өчен махсуслаштырылган учреждениеләргә, махсус укыту-тәрбия учреждениеләренә һәм эчке эшләр органнарының балигъ булмаган хокук бозучылар өчен вакытлыча тоту үзәкләренә күрсәтелгән учреждениеләргә урнаштырылган балигъ булмаганнар белән мәдәният-тәрбия эшләрен оештыруда ярдәм итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин